**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(V чакырылыш)**

җиденче утырыш
**КАРАРЫ**

19 февраль 2026 ел **№ 32** Теләче ав.

«Татарстан Республикасы Теләче
муниципаль районы» муниципаль берәмлеге
милкендәге муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның
фаразлау планын үтәү йомгаклары турында
2025 елга хисапны раслау хакында

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Теләче муниципаль районы Советының 2011 елның 11 июлендәге 53 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында нигезләмә нигезендә, МКУ «Теләче муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» ның 2026 елның 29 нчы январеннән 14 нче номерлы хатын карап, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль район Советы **карар итте:**

1. «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планын үтәү йомгаклары турында 2025 елга хисапны расларга.
2. Әлеге карарны Россия Федерациясенең рәсми сайтында, сәүдә үткәрү турында мәгълүмат урнаштыру өчен, «Интернет» челтәрендә https://torgi.gov.ru/new/public, Теләче муниципаль районының рәсми сайтында tulashi.tatarstan.ru да бастырырга.

Теләче муниципаль
районы Башлыгы А.Г. Фатхуллин

Теләче муниципаль район Советының 2026 елның 19 нчы февраленнән 32 нче номерлы карарына кушымта

# ХИСАП
## 2025 елга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы милкендәге муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планын үтәү йомгаклары турында

«Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советының 2024 елның 25 декабрендәге 292 номерлы «2025 елга муниципаль милекне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) турында» карары нигезендә, муниципаль милеккә караган объектларны хосусыйлаштыруга әзерлек чаралары үткәрелде.

Фараз планы белән билгеләнгән муниципаль милекне хосусыйлаштыруның төп бурычы - район бюджетының керем өлешен тулыландыру, муниципаль милек структурасын оптимальләштерү хисабына, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен кулланылмаган, федераль законнар белән билгеләнгән җирле үзидарә органнарының аерым вәкаләтләрен үтәү өчен кулланылмаган милекне хосусыйлаштыру.

2025 елда сату үткәрелде:

- җир кишәрлеге белән 1 берәмлек күчемсез мөлкәт, 2071000 сумлык (ике миллион җитмеш бер мең өч йөз кырык) 3 берәмлек муниципаль мөлкәт, электрон формада, бәя турында тәкъдимнәр бирүнең ачык рәвешендә, «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон һәм РФ Хөкүмәтенең «Дәүләт яки муниципаль мөлкәтне электрон рәвештә сатуны оештыру һәм уздыру турында» 2012 елның 27 августындагы 860 номерлы карары белән каралган тәртиптә.

Хосусыйлаштыра торган муниципаль милекнең башлангыч бәясе 1998 елның 29 июлендәге 135-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында» Федераль законга туры китереп башкарылган бәяләү хисаплары нигезендә билгеләнде.